БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 04 2021 ел № 142

**2021 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча җәмәгать эшләрен оештыру турында**

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Иҗтимагый эшләрне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары һәм «Татарстан Республикасында җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» (2020 елның 30 декабрендәге үзгәрешләр белән) 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елда Балтач муниципаль районы территориясендә оештырыла торган җәмәгать эшләре төрләре Исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач муниципаль районы территориясендә җәмәгать эшләрен Исемлек нигезендә төрләр буенча 45 эш урынына оештырырга.

3. «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- эшсез гражданнарга туры килә торган эшне эзләү максатларында, оештырыла торган җәмәгать эшләренең төрләре һәм аларны үткәрү тәртибе, шартлары, режимнары һәм хезмәт хакы турында, шулай ук әлеге эшләрне башкарганда оешмалар тарафыннан бирелә торган ташламалар турында халыкка, шулай ук «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ндә теркәлгән затларга хәбәр итәргә;

- эш бирүчеләр белән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты белән берлектә җәмәгать эшләрен оештыру буенча уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә;

- җәмәгать эшләрендә катнашу өчен гражданнарны оешмаларга җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге эш бирүчеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ белән җәмәгать эшләрен оештыру буенча уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә;

- җәмәгать эшләрендә катнашу өчен «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән вакытлы хезмәт килешүләре төзергә;

- җәмәгать эшләрен оештыру һәм уздыру буенча уртак эшчәнлек турындагы килешү нигезендә оештырылган эш урыннарында гражданнарның мәшгульлеген тәэмин итәргә;

- җәмәгать эшләрендә эшләүче эшсез гражданнарга матди ярдәм түләүне үз вакытында башкарырга.

5. «2020 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2020 елның 10 мартындагы 119 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatar.ru) халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район
башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 03.04.
142 номерлы карарына
кушымта

2021 елда Балтач муниципаль районы территориясендә оештырылучы иҗтимагый эшләрнең төрләре

## Авыл хуҗалыгы

Авыл хуҗалыгы корткычларына каршы көрәш;
территорияне төзекләндерү;
яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерү һәм җыю;
техник культураларны игү һәм урып-җыю;
үсентеләрне сайлап утырту;
органика чыгару;
терлек чалу;
терлек азыгы, печән әзерләү;
авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау һәм эшкәртү;
торфлы чүлмәкләр ясау;
терлекчелек биналарын механикалаштыру;
архив документларын эшкәртү;
азык культураларын эшкәртү һәм урып-җыю;
агач кисү;
авыл хуҗалыгы техникасына хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау;
авыл хуҗалыгы объектларының түбәләрен кардан чистарту;
бәрәңге сайлау;
чәчүгә әзерлек һәм чәчү эшләре;
туфракны әзерләү;
элеваторларны эшкә әзерләү;
агач үсентеләрен утырту;
утыртмаларны йомшарту;
вахтер, сакчы булып эшләү;
җәнлек фермасында эш;
пилорамада эш;
ындыр табагында (токта), ашлык кабул итү пунктында эш;
машина белән сыер саву операторы эше;
теплица-бакча хуҗалыкларында эшләр;
терлекләрне тоту һәм көтүгә бәйле вакытлыча эшләр;
азык - төлек һәм эшкәртү предприятиеләрен реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыру эшләре;
иске фермаларны сүтү;
кычыткан чабу;

терлекчелек һәм склад биналарын ремонтлау;
тара ремонтлау һәм әзерләү;
хайваннар өчен дару үләннәре җыю;
җиләк җыю;
авыл хуҗалыгы язгы кыр эшләрен башкарганда сезонлы эшләр;
салам эскертләү;
слесарь эшләре;
яшелчәләрне һәм җиләк-җимешләрне сортларга аеру;
хайваннарның йонын алу;
төзелеш-ремонт эшләре;
кырлардан таш җыю;
икмәк кабул итү пункты территориясен җыештыру;
урып-җыю эшләре;
яшелчәләрне һәм җиләк-җимешләрне саклау өчен урнаштыру;
чүп үләннәрен юк итү;
хайваннарны карау;
мамык тарау;
торак-коммуналь хуҗалыкны эксплуатацияләү;
башка эшләр.

## Төзелеш

Тапшырыла торган объектларны төзекләндерү;
җир эшләре;
маляр һәм штукатур эшләре;
бүрәнәләләрне шомарту;
төзелеш материалларын ташу;
суүткәргеч, газ, канализация һәм башка коммуникацияләрне салганда ярдәмче, икенчел һәм башка эшләр, авыл хуҗалыгы сугару (ирригацион) эшләрен башкару һ.б.;
кирпеч җитештерү;
төзелеш материаллары җитештерү;
иске кирпеч өемнәрен сүтү;
терлекчелек биналарын ремонтлау;
социаль-мәдәни-көнкүреш объектларын ремонтлау;
башка эшләр.

## Сәнәгать

Үзгәртеп кору һәм профилен үзгәртү чорында предприятиеләрдә квалификацияләнмәгән эшләр башкару;
агач эшкәртү;
биналарга һәм цехларга косметик ремонт ясау;
производство һәм производствоныкы булмаган биналарның тәрәзәләрен юу;

предприятиеләр территорияләрен кардан чистарту;
кыргый үсемлекләрне эшкәртү;
урман эшкәртү;
авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү;
теплица хуҗалыкларында, ит комбинатларында, җитен заводларында, кирпеч заводларында һәм башка предприятиеләрдә ярдәмче эшләр;
махсус кием тегү;
заводта сөт кабул итү;
агач материаллар җитештерү, буралар ясау һ. б.;
тегү цехларында эш;
биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау эшләре;
күмерне сортировкалау һәм юдыру эшләре;
электртапшыргыч линияләр трассаларын чистарту һ.б.;
тара ремонтлау һәм әзерләү;
җиһаз (мебель) ремонтлау;
икенчел чимал һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртү;
папкалар ябыштыру;
слесарь эшләре;
пыяла савытларны сортировкалау;
территорияне җыештыру, төзекләндерү һәм яшелләндерү;
көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү;
сызым эшләре;
башка эшләр.

Урман хуҗалыгы

Урман корткычларына каршы көрәш;
урманнарны янгыннардан соң торгызу (кисеп ташлау, кисү);
куакларны, агачларны кисү, печән чабу, территорияне чүптән чистарту, чүп чыгару эшләре;
чыршы һәм чыршы бәйләмнәре әзерләү;
урман, чыбыклар, салам әзерләү һ. б.;
урман орлыклары әзерләү;
яшелләндерү;
урман бүлемнәрен (делянкаларын) кисемтә калдыкларыннан чистарту;
питомниклар һәм урман утырту өчен туфрак әзерләү, утыртмаларны карау;
үсентеләр утырту, аларны агротехник карау;
пилорамада эш;
урманнарны чүптән һәм пычратудан чистарту;
дару үләннәрен, кыргый үсемлекләрне, кыргый үсә торган җимешне, чикләвекне, ылыслы агачларның күркәләрен җыю һәм әзерләү;
урман-парк хуҗалыгын саклау һәм үстерү;
урман хуҗалыкларында исәп эшләре;
урман материалларын штабельгә салу;
башка эшләр.

## Юл төзелеше

Тротуарларны һәм йөрү юлларын урнаштыру, төзекләндерү;
агач үсентеләрен үстерү һәм карау, күренүне тәэмин итү өчен ботаклар кисү;
юлларны сүтү;
җир эшләре өчен киртәләр урнаштыру;
кар саклый торган калканнар (щитлар) ясау, ремонтлау һәм урнаштыру;
юлларны төзекләндерү элементларын буяу, аларны чисталыкта һәм тәртиптә тоту;
юл катламының (полотносының) янтүшәмәсе (отмосткасы);
юл катламнарын пычрактан һәм кардан чистарту;
сууткәргеч торбаларны, күпер һәм юлүткәргеч элементларын пычрактан, кардан һәм боздан чистарту, торбаларны ачу һәм ябу;
юл кырыйларын планлаштыру;
сууткәргеч системасын тоту эш хәлендә саклап калу;
җир полотносының сөзәк урыннарында тотрыклы агач өслеген булдыру буенча кирәкле агротехник чаралар үткәрү;
юлларны төзү һәм ремонтлау вакытындагы эшләре;
асфальт җәю;
юл конструкцияләрен ремонтлау;
юл катламын (полотносын) ремонтлау һәм төзү;
күперләрне ремонтлау;
юл кырыйларында, откосларда, фермаларда һәм бүлеп бирелгән полосада үләннәрне чабу һәм куакларны кисү, кисемтә калдыкларын җыю;
автобус тукталышларын, мәйданчыкларны һәм аларны төзекләндерү элементларын чисталыкта һәм тәртиптә тоту;
җәяүлеләр өчен тротуарлар төзү;
кар саклау, урман полосаларын карау;
башка эшләр.

## Сәүдә һәм җәмәгать туклануы

Базар территориясен төзекләндерү;
лотокта сәүдә итү;
савыт-саба юу;
халыкны сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү;
яшелчәсаклагычларны чистарту һәм әзерләү;
йөк ташу;
тара ремонтлау һәм әзерләү;
ремонт-торгызу һәм кар чистарту эшләре;
кафе, ашханә биналарын җыештыру һ. б.;
әзер продукцияне төрү;
башка эшләр.

## Торак-коммуналь хуҗалык

Бордюрларны бетонлаштыру һәм буяу;
территорияләрне төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту;
истәлек билгеләрен торгызу һәм алыштыру;
храмнарны, мәчетләрне торгызу һәм реставрацияләү һ. б.;
тарихи-архитектура һәйкәлләрен, ял зоналарын, мәдәният паркларын, скверларны торгызу һәм саклау: яшелләндерү, утырту, чүбен утау, чәчәк түтәлләренә су сибү, агачның очларын кисү, агачларны кисү һәм үсентекләрне җыештыру, печәнне чабу һ. б.;
территорияләрне, сулыкларны экологик савыктыру чаралары;
пляжларны чистарту;
гравий һәм ком сибү;
хәрби каберлекләрне, мемориалларны, күмәк каберлекләрне, зиратларны тәртипкә китерү, җирләү урыннарын карап тоту һ. б.;
җылылык бирү сезонына әзерлек буенча эш;
энергия, газ, җылылык һәм су белән тәэмин итүне һәм канализацияне карап тоту һәм үстерү эшләре һ. б.;
торак пунктлар территорияләрен экологик савыктыру эшләре;
торакны газлаштыру буенча эшләр;
иске йортларны сүтү;
кардан чистарту һәм катоклар катыру;
күперләрне ремонтлау;
мичләрне ремонтлау;
квартал эчендәге территорияләрне һәм контейнер мәйданчыкларын чүптән һәм көнкүреш калдыкларыннан санитар чистарту;
үзирекле корылмаларны сүтү;
торак фондын һәм социаль-мәдәни-көнкүреш объектларын (мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, спорт мәйданчыклары, мәдәният, сәламәтлек саклау учреждениеләре, картлар һәм инвалидлар йортлары һ. б.) карап тоту һәм куллану һ. б.;
кунакханә номерларын җыештыру;
торак йортлардагы бүлмәләрне, баскыч мәйданчыкларын җыештыру;
түбәләрне һәм территорияләрне кардан чистарту;
коймалар урнаштыру;
мемориаль плитәләр урнаштыру;
күпкатлы йортларның подъезд ишекләрен, тәрәзәләрен җылыту;
башка эшләр.

## Транспорт һәм элемтә

Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру;
телефон линияләре баганаларын алыштыру;
элемтә линияләрен сузу буенча җир эшләре;
автотранспортны юу;

шәһәр пассажир транспорты эшенә мониторинг;
элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү;
тимер юл полотносын чистарту;
станция һәм керү юлларын чистарту;
төяү-бушату эшләре;
локомотив депосында ярдәмче эшләр;
пассажир транспортына, почта һәм элемтә оешмаларына хезмәт күрсәтү;
халыкка һәм учреждениеләргә транспорт хезмәте күрсәтүдә ярдәм;
җәмәгать транспортында кондукторлар һәм пассажирлар счетчиклары сыйфатында эш;
элемтә бүлекчәләрендә хат ташучылар эше;
проводник эше;
станцион эшчеләр эше;
телефон кабеле салу буенча эшләр;
юл йөрү билетларын тарату;
тимер юл платформаларын кардан чистарту;
тимер юлларны ремонтлау һәм төзү;
сезонлы эшләр (товарлар ташу, кар җыештыру һ. б.);
суднолар ремонты эшләре;
автотранспорт биналарын җыештыру;
башка эшләр.

Сәламәтлек саклау, физик культура
һәм социаль хезмәт күрсәтү

Сулыкларны һәм подвалларны дезинсекцияләү;
балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне һәм ял иттерүне тәэмин итү;
халыкка социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү (бакчалар казу, утын әзерләү, фатирларга косметик ремонт ясау һ. б.);
тамаша чараларына (фестивальләргә, спорт ярышларына һ. б.) хезмәт күрсәтү;
биналарга хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонт;
якын-тирә территорияләрне, ял һәм туризм зоналарын яшелләндерү һәм төзекләндерү;
спорт лагерьларында балаларның ялын оештыру;
пенсия эшләрен рәсмиләштерү;
өс киемнәрен кабул итү һәм бирү;
халыкны һәм муниципаль учреждениеләрне ягулык белән тәэмин итү;
муниципаль берәмлектә физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру һ. б.;
кер юу;
өлкәннәрне, инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны тәрбияләү;
документларны теркәү һәм рәсмиләштерү;

ветераннар өчен бүләкләр формалаштыру, котлау открыткаларын, бәйрәм чараларында катнашу өчен чакыруларны әзерләү һәм аларны адреслы илтеп тапшыру;
башка эшләр.

### Мәгариф, мәдәният, сәнгать һәм фән

Археологик казу эшләре;
территорияне төзекләндерү;
җәйге вакытта балалар мәйданчыкларында тәрбиячеләр;
аттестатлар тутыру;
экспонатларга һәм экспозиция залларына косметик ремонт ясау;
аттракционнарга, мәдәни билгеләнештәге тамаша чараларына (фестивальләр, бәйрәмнәр, конкурслар) хезмәт күрсәтү;
китапханә өлкәсенә хезмәт күрсәтү;
биналарга, бүлмәләргә хезмәт күрсәтү;
мәдәният учреждениеләрендә, хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру;
яшьләрнең ялын оештыру;
Яңа ел чыршысын саклау;
мәдәни-массакүләм чараларны әзерләү һәм үткәрү;
Мәктәпкәчә, төп гомуми һәм һөнәри белем бирү муниципаль учреждениеләрен оештыруда, карап тотуда һәм үстерүдә, мәдәният учреждениеләрендә, балалар бакчаларында, пионер лагерьларында балаларның ялын оештыруда, мәктәпкәчә учреждениеләрдә утын өюдә ярдәм итү;
экскурсовод-лектор эше;
методист эше;
сәхнә монтажлаучы эше;
музей-күргәзмә комплексы хезмәткәре эше;
җәйге чорда балалар мәйданчыкларында эшләр;
балигъ булмаганнарның җәйге хезмәтен оештыру буенча эш;
китап, җиһаз (мебель) ремонтлау;
мемориаль мәйданчыкларны ремонтлау, ветераннар һәм сугышларда катнашучылар өчен стендлар, планшетлар, альбомнар ясау;
укучылар бригадалары белән җитәкчелек итү;
мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыру (мебель, җиһазлар урнаштыру, афишалар ябыштыру һ. б.);
балаларны мәктәпкә озату;
башка эшләр.

### Идарә

Архивларны оештыруда һәм карап тотуда ярдәм (архивка документлар тапшыру буенча эшләр, хуҗалык китаплары булмаган китапларын урнаштыру һ. б.);

ветераннарның мәгълүматлар базасын чагыштыру;
җирдән файдаланучылар исемлекләрен төзү;
әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын үткәрүдә катнашу, су объектларын кулллануны җайга салу (мелиорация эшләре үткәрү, сулыкларны сәламәтләндерү, коелар казу һ.б.);
федераль һәм региональ (төбәк) иҗтимагый кампанияләрен үткәрүдә катнашу (статистик, социологик тикшеренүләрне, халык санын алуны, авыл хуҗалыгы исәбен алуны, терлек санын алуны, җәмәгатьчелек фикерен сораштыруны үткәрүдә катнашу, сайлау комиссияләрендә эшләү һ. б.);
адреслы хуҗалыкның торышын тикшерүдә катнашу;
башка эшләр.

## Башкалар

Машинада язу (печатьләү) эшләрен башкару;
шәхси затлар гаризалары буенча вак ремонт-төзелеш һәм авыл хуҗалыгы эшләрен башкару;
маймычлар үстерү;
яшелчә өчен сеткалар бәйләү;
хуҗалык китапларын тутыру;
мех әйберләре ясау;
юрганнар зерләү;
урам исемнәре, йорт номерлары язылган табличкаларны яңарту;
экологик эшләрне оештыру һәм үткәрү;
йон эшкәртү;
язгы кәрванда төяү-бушату эшләре;
укучыларны вакытлыча эш белән тәэмин итү өчен эш урыннары әзерләү;
нәшриятларда ярдәмче эшләр;
гардеробта эш;
кастелянша эше;
лаборант эше;
басма матбугат тарату;
реклама тарату;
геологик экспедицияләрдә сезонлы кыр эшләре;
гуманитар ярдәмне сортировкалау;
башка эшләр.